**Р.С.Нурмөхәммәтова,**

**Казан федераль университеты, Казан**

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КЕШЕНЕҢ МИЛЛИ ХАРАКТЕРЫН ЧАГЫЛДЫРА ТОРГАН СҮЗЛӘР

(Мәкалә 14-14-16019 номерлы РГНФ гранты кысаларында язылды.)

**Аннотация**. В связи с глобализацией экономических, политических, культурных связей под угрозу ставится существование индивидуально-национальных черт в характере человека. В статье дается общий обзор лексем, отражающих этнические особенности татарской языковой личности. Осмысление исторического опыта народа, зафиксированного в лексике языка, способствует переоценке ценностей современного мира и возродит интерес к проблеме национального характера.

**Abstract**. The existence of individual and national features of the person character is under the threat according to economic, political and cultural globalization. The article provides an overview of lexical units, reflecting the ethnic features of a Tatar language person. Understanding of the historical experience found in the vocabulary of the language facilities reappraisal of values of the modern world and inspires a renewed interest to the national problems.

Икътисади, сәяси һәм мәдәни багланышларның глобализациясе шартларында кешедәге шәхси-милли башлангычны саклау мөһим мәсьәләләрнең берсенә әверелә бара. Узган гасырларның тарихи тәҗрибәсен барлау, халыклар арасындагы конфликтларның сәбәбен ачыкларга тырышу һ.б. милли характер проблемаларына дөньякүләм масштабларда кызыксыну уята.

Кызганычка каршы, соңгы елларда матди байлык артыннан куу аркасында кешеләр бер нәрсәне онытып җибәрде: төрле кешеләрне бары тик «халык», «милләт» дигән төшенчәләр генә берләштерә ала бит. Тулаем югалмаса да, күпмедер дәрәҗәдә үз халкың, аның тарихы белән горурлану, аның киләчәгенә өмет какшый бара.

Хәзерге вакытта иҗтимагый-мәдәни модельләрдә катлаулы үзгәрешләр бара, бу шартларда шәхеснең үзбилгеләнеше дә шактый катлаулана. Элек дөнья турында күзаллаулар һәм нормалар барлыкка китерүдә тотрыклы милли мәдәният төп нигез булса, хәзерге иҗтимагый вәзгыять шәхескә юнәлеш сайлауда мөстәкыйльлек бирә. Шуңа күрә дә бүгенге көндә ата-аналар, тәрбиячеләр, педагоглар яшьләрнең шушы сайлау иреге алдында югалып калмавын тәэмин итәргә, гомумкешелек кыйммәтләрен аңлатырга, ата-бабалардан килгән милли сыйфатларны саклап, киләчәк буыннарга җиткерүгә омтылыш тудырырга, үз милләтенә карата горурлык хисе уятырга тиеш.

Бу эштә телне төрле яклап тирәнтен өйрәнү дә ярдәм итә ала. Әлеге хезмәтнең максаты – татар теле лексикасында милли характерны билгели торган сүзләргә гомуми планда күзәтү ясау. Татар теленең лексик байлыгы моңа кадәр тел шәхесен тасвирлау максатында сирәк кулланылганлыктан, бу эш әлеге юнәлештә бер омтылыш булып тора.

Башка барлык телләр кебек үк, татар теле дә дөньяны кабул итүнең билгеле бер ысулын чагылдыра. Татар сүзләренә һәм гыйбарәләренә салынган төрле мәгънәләрдә теркәлгән дөнья турындагы күзаллаулар бердәм карашлар системасына җыела. Бу карашлар исә теге яки бу дәрәҗәдә бөтен татарча сөйләшүчеләр арасында бүленгән була.

Табигый, төп мәдәни йөкләнмә лексикага – сүзләргә һәм сүзтезмәләргә салына. Алардан әлеге тел вәкилләренең дөньяны кабул итүен билгели торган дөнья тел сурәте барлыкка килә. Телнең лексик составын тәшкил иткән элементларның шәхес формалашуда төп роль уйнавы бәхәссез. Әмма бу бары лексикага гына «мәдәни катлам» салынганлыгын аңлатмый. Тел шәхесе формалашуда телнең барлык (морфологик, синтаксик, стилистик) чаралары да катнашуын истә тотарга кирәк.

Аерым бер халыкка хас булган сыйфатларның асылын билгеләү – әлеге халыкның билгеле бер иҗтимагый-икътисади яшәешендә, мәдәниятендә һәм традицияләрендә гомумкешелеккә хас сыйфатлар чагылышын тикшерү дигән сүз. «Хәзерге заман кешесеннән әкренләп һәм авырлык белән барлыкка

китерелгән йолаларын, гореф-гадәтләрен, барлык шартлылыкларны тартып алып карагыз, ул югалып калачак, тормыш итү зирәклеген югалтачак, якыннары белән үзен ничек тотарга кирәклекне белмәячәк, һәм барысын да өр-яңадан башларга тиеш булачак», – дип яза В.О.Ключевский [2, 433]. Бу фикерләр белән килешми мөмкин түгел. Үз тамырларыннан аерылган, гореф-гадәтләрне белмәгән кешеләрнең чит җирләрдә ничек яшәве турында күп языла, күп сөйләнелә. Кеше үз җирендә яшәгәндә, гадәттә, мондый шартлылыкларга игътибар итеп тормый; үз этник төркеменә хас үзенчәлекләр турында да әллә ни уйланмый.

Татар кешеләренә хас сыйфатларны махсус өйрәнеп язылган фәнни хезмәтләр күп түгел. Бары соңгы елларда лингвокультурология кысаларында татар теле материалында башкарылган хезмәтләрдә намуслылык, шәфкатьлелек, сабырлык, ярдәмчеллек, хезмәт сөючәнлек, тырышлык кебек сыйфатлар турында сүз алып барыла башлады [1, 170-206]. Бу нисбәттән, җирле сөйләшләр материалында язылган хезмәтләрне дә уңай тәҗрибә буларак атап китү урынлы булыр [4, 179-244].

Рус милли характерын ачыклауга багышланган хезмәтләрдә милли характер формалашуда табигый шартларның, диннең һ.б. роленә басым ясала. Руслар һәм татарларның бер үк табигый-географик шартларда тормыш итүләрен игътибарга алганда, әлеге фикерләрне татарлар өчен дә кулланырга мөмкин дип саныйбыз. Чыннан да, кырыс табигый шартлар безнең халыкта да *чыдамлылыкны, тырышлыкны, авыр хезмәткә сәләтлелек*не арттырган. Россиянең зур киңлекләргә таралуы халкыбызда *киң күңеллелек, кунакчыллык, бердәмлек, дуслык, үз-үзеңне саклау* һәм *бер-береңә ярдәм* итү сыйфатларын тәрбияләгән. Матди яктан авыр тормыш *булганына канәгать булу, гадилек, сабырлык, түземлелек*кә китергән.

Милли дөнья тел сурәте халыкның төп үзенчәлекләрен ачып бирә торган төшенчәләрдән формалаша. Татар кешесе өчен алар *җан, язмыш, сагыш, бәхет, намус* кебек сүзләр ярдәмендә бирелә [6, 4]. Бу сүзләрнең мәгънәләренә салынган күзаллаулар карашлар системасын формалаштыра һәм әлеге тел

вәкилләренең барысы өчен дә мәҗбүри буларак кабул ителә. Кеше сүзләрне кулланганда аларга салынган мәгънәләр турында уйлап тормый, ул бары тик аларга теркәлгән дөньяга карашны ышанып кабул итә. Ә башка бер тел вәкиле әлеге мәгънәви компонентларга шикләнеп карарга һәм бәхәскә керергә мөмкин.

Һәрбер табигый телдә билгеле бер мәдәният өчен гаять мөһим булган бер төркем сүзләр яши. Алар мәдәни һәм милли идеалларны, милли характерны чагылдыралар, үзләренең мәгънәләрендә халыкның тәҗрибәсен, әхлакый карашларын саклыйлар. Нәкъ менә шуңа да ул төркемгә кергән сүзләр синонимнарга бай булуы белән аерылып тора.

Татар халкында кешене характерлаганда шәхеснең рухи ягы, эчке дөньясы белән бәйле сыйфатлары аның мөһим билгеләре буларак бәяләнә. Татарларда белемгә омтылыш элек-электән югары бәяләнгән: ***укымышлы*** *– белемле, укыган, мәдәни, мәдәниятле, мәдәниләшкән, белекле, белгән, мәгърифәтле, мәгълүматлы, хәбәрдар, абыз, зыялы, зыя, культуралы, интеллегент* [7, 101]; надан кешеләргә исә түбәнсетеп караганнар: ***надан*** *– грамотасыз, укый-яза белмәүче, укый-яза белми торган, белемсез, укымаган, томана, белексез, кара, караңгы, җаһил* [7, 72].

Үзара мөнәсәбәтләрдә бер-береңә йомшак, игътибарлы булу, өлкәннәргә һәм кечкенәләргә ярдәм итү кебек сыйфатларга өстенлек бирелгән: ***шәфкатьле*** *– мәрхәмәтле, миһербанлы, рәхимле, кызганучан, аяучан, хәлгә керүчән, рәхим-шәфкатьле, кешелекле, йомшак күңелле, кече күңелле, гуманлы, мәрхәмәт иясе, шәфкать иясе, яхшы күңелле, изге күңелле* [7, 115].

Хезмәт сөю уңай сыйфат буларак бәяләнгән: ***уңган*** *– булдыклы, булган, эшлекле, эшчән, эшмәкәр, эшкә оста, булдыра торган, кулы эш белгән, өлгер, алтын куллы, оста, кулга оста, сәләтле* [7, 101]; ә ялкауларны халык бер дә өнәмәгән: ***ялкау*** *– иренчәк, наян, үшән, иренгән, суйлак, эшлексез, тик йөрүче* [7, 122] һ.б.

Бу фикерләрне халыкның буыннан-буынга тапшырылып килгән мәкальләре белән дә дәлилләргә була: *Уңган* уңыш табар (37818); *Уңган* булсаң, дус итәрләр кай илләргә барсаң да (20811); Сорама байдан, сора *шәфкатьле*дән

(25181); *Белемле* үлмәс, белешсез көлмәс (20660); Юлдашың *белемле* кеше булса, юл кыска булыр (22163); *Белемсез* әдәмнең сүзе беләктәй, *белемле* әдәмнең сүзе ефәктәй (28236); Ярлы *ялкау* була (25361) һ.б. [3].

Телнең лексик байлыгы буенча фикер йөрткәндә, татар халкы кешедәге уңай сыйфатлар дип санаган түбәндәге билгеләрне күрсәтергә мөмкин: *белемлелек, шәфкатьлелек, денлелек, гадилек, кыюлык, намуслылык, юмартлык, хезмәт сөючәнлек, туган җирне ярату* һ.б. Болар тел шәхесен тасвирлаганда төп компонентларны тәшкил итә. Әлеге сыйфатлар капма-каршы төшенчәләр белән янәшә куелганда гына бөтен тулылыгы белән ачыла, аларның кеше тормышында әһәмияте исбатлана. Бәлки шуңадыр да, татар телендә бу мәгънәләргә нисбәтле уңай һәм тискәре сыйфатлардан торган антонимик парлар шактый күп. Мәсәлән, *абруйлы – абруйсыз, акыллы – надан, акыллы – тиле, ачык – йомыкый, әдәпле – дорфа, базык – базымчан, батыр – куркак, ваемлы – ваемсыз, вөҗданлы – вөҗдансыз, гадел – залим, игелекле – усал, изге – явыз, ихлас – икейөзле, куркак – кыю, максатчан – максатсыз, намуслы – намуссыз, оялчан – оятсыз, пөхтә – шапшак, сабыр – түземсез, сәләтле – сәләтсез, талантлы – талантсыз, тәкәбберлек – тыйнаклык, тискәре – җайлы, тотнаклы – тотнаксыз, тырыш – ялкау, уңган – ялкау, хәйләкәр – беркатлы, һөнәрле – һөнәрсез, эшчән – ялкау, эшлекле – эшлексез, юаш – усал, юньле – юньсез, ягымлы – ачулы, яхшы – юньсез* һ.б. [5].

Милли характерның булуын, аның яшәешен халык авыз иҗаты, матур әдәбият әсәрләре нигезендә дәлилләргә мөмкин. Әмма иң ышанычлы һәм фәнни яктан нигезле чыгынак – милли тел. Тел үз «хуҗасын» чагылдыра да, формалаштыра да, ул – халык характерының объектив күрсәткече.

Файдаланылган әдәбият

1. Замалетдинов Р.Р. Теоретические и прикладные аспекты татарской лингвокультурологии. – Казань: Магариф, 2009. – 351 с.

2. Ключевский В.О. О русской истории: Сборник / Под ред. В.И. Буганова. – М.: Просвещение, 1993. – 576 с.

3. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре: 3 томда. Т.3. – 2-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 800 б.

4. Рамазанова Д.Б. Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика. – Казан, 2013. – 364 б.

5. Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.М. Татарча-русча антонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1997. – 96 б.

6. Татарская лингвокультурология: концепты духовного мира человека / Р.Р. Замалетдинов, Г.Ф. Замалетдинова, Р.С. Нурмухаметова, З.А.Мотыгуллина и др. – Казань, 2012. – 300 с.

7. Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999. – 256 б.